ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

6 декабрь, 2019 ел № 34/15

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/7 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 07.04.2016 ел № 7/20, 21.02.2018 ел № 23/12, 08.11.2018 ел №27/22 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 статьяның 1 пунктындагы 12 пунктчасында «тулы булмаган белешмәләр» сүзләреннән соң «,әгәр федераль законнар белән башкасы билгеләнмәгән булса,» сүзләрен өстәргә;

2) 17 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасында «, шулай ук үз эше турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев